*Муниципаль тур*

**Рус телендә белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен олимпиада биремнәре**

***2017/2018 нче уку елы*** **VIII сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут Максималь балл -58**

**I. Сүзләрне басымнары кайсы иҗеккә төшүе ягыннан төркемләгез.**

Кайталар, килегез, кемнәр, сиздерсәң, нәрсәгә, сөйлиләр, эшләгән, көләчәк, татарча, уйчанлык, нишлиләр, сүзлекчә, ниндидер, дускайлар, кайчан

а) беренче иҗеккә:

ә) икенче иҗеккә:

б) өченче иҗеккә:

**II. Берәр дөрес җавапны табыгыз.**

1. Күп ноктaлар урынына “ө” хәрефе язылa торган сүзләр генә булган рәтне табыгыз:

а) г...мер, к...дрәт, х... рмәт;

ә) к...меш, м...бaрәк, т...бәк;

б) г...реф-гадәт, тимер-т...мыр, м...нбәр;

в) м...нәсәбәт, м...гъҗиза, б...җра.

2. Борын ассимиляциясе күзәтелгән сүз кергән мәкальне билгеләгез:

а) Иле барның теле бар;

ә) Һәркемгә үз иле газиз;

б) Үзеңнән яман белән дус булма;

в) Холкы начардан дуслары качар.

3. Дүрт аваздан торган сүзләр рәтен күрсәтегез:

а) таяк, агач;

ә) аваз, быел;

б) бүре, кояш;

в) алма, һава.

4. Бирелгән сүзләр кайсы принципка нигезләнеп язылган?

*Унбиш, төнбоек, көнбагыш*

а) фонетик принцип;

ә) морфологик принцип;

б) тарихи-традицион принцип;

в) дөрес җавап бирелмәгән.

5. *Сөзгеч, бүлек, кадак* сүзләренең тамырлары нинди сүз төркеменә карый?

а) исем;

ә) рәвеш;

б) фигыль;

в) сыйфат.

6. Сүз ясалышы ягыннан караганда, кайсы рәттәге сүзләр «артык»?

а) энем, эшем;

б) кием, бүлем;

в) бирем, чыгым;

б) керем, сызым.

7. Тамырдаш сүзләр генә булган рәтне күрсәтегез:

а) аклык, агару, акация;

ә) язын, язмыш, язма;

б) юлдаш, юлчы, юллама;

в) дөрес җавап бирелмәгән.

8. Мәгънәдәш сүзләрне бер-берсенә теркәү юлы белән ясалган парлы сүзләр рәтен билгеләгез:

а) берән-сәрән, бүләк-санак, аз-маз, бала-чага;

ә) бәйнә-бәйнә, чиле-пешле, елдан-ел, башма-баш;

б) килде-китте, эреле-ваклы, ара-тирә, тирә-юнь;

в) аң-белем, иелә-сыгыла, моң-зар, уй-фикер.

9. *“Саннар нинди ысуллар белән ясала?”* дигән сорауга ялгыш җавапны билгеләгез:

а) тезү юлы белән ясала;

ә) кушу юлы белән ясала;

б) ясагыч кушымча ярдәмендә ясала;

в) парлау юлы белән ясала.

10. Өч төрле заман формасындагы фигыльләр кулланылган мәкальне табыгыз.

а) Уйнап сөйләсәң дә, уйлап сөйлә;

ә) “Үзем беләм” дигән үргә йөзмәс;

б) Иренсәң – иренеңә тимәс;

в) Абынмас җирдә абынма, абруең төшәр.

**III. Бирелгән хәрефләрнең барысын да файдаланып, исем сүз төркеменә кергән бер сүз язызыз**.

**Р Е А Ү**

**Н Ш Т Е К М**

**IV. Иҗади бирем.**

**“Минем дәү әтием (әнием)” дигән темага 8 җөмләдән торган хикәя төзеп языгыз.**